ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 август 2022 ел № 4006

Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2836 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174.3 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2836 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә, 4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеге агымдагы елның 1 декабренә кадәр Башкарма комитет карары белән раслана һәм агымдагы елның 15 декабреннән соңга калмыйча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов